**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №203-38 «11» декабрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2021 елның 29 ноябрендәге 56-12 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмә хакында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында " 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2021 елның 29 ноябрендәге 56-12 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмә хакында» гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә (25.02.2022 №75-15, 08.06.2023 №133-22, 25.10.2023 №152-24 карарлар редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының карарына №1 кушымта

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә №2 кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда контроль чаралар үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Муниципаль торак контроле органы адресына гражданнардан кергән (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен ачыкларга мөмкинлек биргән ысул белән) һәм күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре булган оешмалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуның фактлары турында дәүләт мәгълүмат системаларыннан булган күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре булган гражданнар өчен мөрәҗәгатьләр санының өч мәртәбә һәм аннан күбрәк үсеше.

2. Көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча чишелешләр булган муниципаль торак фондының торак урыннары булган күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышының өч ай рәттән ике һәм аннан да күбрәк беркетмәләре муниципаль торак контроле органына керү.

3. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Торак кодексының 165 статьясындагы 5 өлеше нигезендә билгеләнгән урнаштыру тәртибе, рәвешләре, сроклары һәм вакыты нигезендә урнаштырылырга тиешле мәгълүматны өч һәм аннан артык ай дәвамында актуальләштерүнең булмавы.